**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Сармаш-Баш авыл җирлегенең Федоровка торак пунктында**
**2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**

**21.11.2025 ел** **№ 1**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Сармаш-Баш авыл җирлеге Уставы, Федоровка торак пунктында гражданнар җыены нигезендә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы авыл җирлеге Федоровка торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сармаш-Баш авыл җирлегенең Федоровка торак пунктында теркәлгән. балигъ булган һәр гражданга, I төркем инвалидлардан, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, 2026 елда үзара салымны 600 сум күләмендә билгеләргә

2.Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:
-җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (чишмәләрне төзекләндерү).

3.Карарны кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә (Сарма-Баш авыл җирлеге Уставының 69 ст. 5п.) Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сармаш-Баш авыл җирлеге мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Зәй муниципаль районы**
**Сармаш-Баш авыл җирлеге башлыгы Г.П. Абрамов**